Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районының
Арча шәһәр муниципаль берәмлеге
Арча шәһәр Советы
422000, Арча ш. Совет мәйданы, 27

тел. 3-16-25, 3-12-35

Муниципальное образование
город Арск
Арского муниципального района
Республики Татарстан
Совет города Арск
422000,г. Арск, площадь Советская , 27

тел. 3-16-25, 3-12-35

**Арча шәһәр Советы**

**КАРАРЫ**

**2025 елның 21 августы** **№157**

**Арча шәһәр Советының аерым карарлары**
**үз көчләрен югалткан дип тану турында**

“Коррупциягә каршы көрәш турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 121 статьясы 42 өлеше һәм “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның һәм “Арча шәһәре” муниципаль берәмлегенең 15 статьясы 8 өлеше нигезендә Арча шәһәре Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәре Советының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип таныргa:

- “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәткә һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат тапшыру турында” Арча шәһәре советының 2016 елның 18 апрелендәге 31 номерлы карары;

- “Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының “Арча шәһәре” муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның керемнәре, чыгымнары, мөлкәткә һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат тапшыру турында” Арча шәһәре Советының 2016 елның 18 апрелендәге 31 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында” Арча шәһәр Советының 2022 елның 7 июнендәге 69 номерлы карары.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

“Арча шәһәре” муниципаль берәмлеге
башлыгы вазыйфаларын башкаручы,
Арча шәһәре Советы рәисе
вазыйфаларын башкаручы Г.Х.Нигмәджанова